# *Туган ягым - Азнакай*



***Без тумыштан моңлы, шаулы халык***
***Азнакайлы, Чатыр таулы халык…***

***Ф.Гыйззәтуллина***

***Гарипова Ләйсән,***
***Татарстан Республикасы***
***Азнакай шәһәре 2 нче урта***
***гомуми белем бирү мәктәбенең***
***11 нче сыйныф укучысы***



***Минем туган ягым- җырларда җырлана торган – Азнакай төбәге. Дөньяның кай җирләрендә яшәсәң дә, нинди генә матур урыннарны күреп сокланса да, туган якның гүзәллеген берни дә алыштыра алмый. Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп аккан йөгерек чишмә буйлары, балыклы күлләр, куе әрәмәләр белән уратылган елга буйлары, туган ягыбызның кырлары күңелгә рәхәтлек биреп, үзенә чакырып тора.***

Җәйрәп ята салкын Ык сулары,
Елгалары, талгын күлләре.
Әсир итә гашыйк күңелләрне
Чишмәләре, елга-күлләре.
Бу - Азнакай ягы -
Шау чәчәкле,
Әкияттәй серле урманнар.
Уйнаганда милли моң чәчәләр
Былбыл телле көмеш тальяннар.
Бу - Азнакай ягы -
Мул көшелле, кырларында алтын көлтәләр
Җир астыннан чыккан хәзинәсен
Кара алтын диеп йөртәләр.
Бу - Азнакай ягы...



*Безнең тарих, безнең эзләр*
*Бик тирәннән килә.*
*Горурмын мин! Үз халкымны*
*Яратканга күрә.*

*И.Гыйләҗев.*








***Туган ягымның данлыклы үткәне, сокландыргыч бай тарихы бар. Аның беренче нигез ташы 1762 елда салына.Беренче тапкыр Азнакай якларын 18 нче гасырда яшәгән танылган галим – сәяхәтче Пётр Симон Паллас үзенең “Путешествие по разным провинциям Российского государства» дигән хезмәтендә искә ала. 1772 – 1773 нче елгы сәяхәт вакытында, Себердән кайтышлый, безнең Азнакай якларында да булган. Емельян Пугачёв җитәкчелегендәге 1773-1775 нче елгы крестьян сугышы бу якларга да килеп җитә.***

***1931 елда Азнакай районы оеша,1987 елда Азнакай шәһәр статусы ала.***

Син каян дип сорасалар,
Чатыр тау иленнән дим.
Кара алтынга бай булган
Мул уңыш җиреннән дим.

И.Гыйләҗев.




**Туган ягым-елның елында республика күләмендә иң югары уңыш үстереп алучы игенчеләр, ярты гасыр вакыт эчендә 500 млн. тоннадан артык “кара алтын”чыгаручы нефтьчеләр төбәге ул.**











***Син безне биеккә күтәрдең,***
***Туган як бәхете – Чатыр тау.***

***Марсель Галиев***








http://Turbik.turbina.ru





ЧАТЫР-ТАУ
334,5м

# Туган яктан илһам алып…





Туган ягымның илгә, дөньяга танылган шәхесләре гаять күп. Олуг гыйлем иясе Ялчыгол, Закир Һади, Зәкиҗан Шаһгәрәев, Ризадтин Фәхретдиннәрнең тормыш юллары да безнең яклар белән бәйле.

***Танылган язучыларыбыз Габдулла Тукай премиясе лауреатлары Мәхмүт Хәсәнов, Марсель Галиев, Россия һәм Татарстанның халык артистлары Нәҗибә Ихсанова, Әзһәр Шакиров, күренекле җырчыларыбыз Зәйнәп Фәрхетдинова, Равиль Галиев, Данир Сабиров, Россия герое Ильяс Дауди һәм тагын бик күп шәхесләребез районыбызның данын еракларга таныттты.***


Нур Гариф улы ӘХМӘДИЕВ


Марсель Баян улы ГАЛИЕВ


Илдус Сабир улы ГЫЙЛӘҖЕВ



**Әзһәр Шакиров**

**Нәҗибә Ихсанова**







**Данил Сабиров**

**Зәйнәп Фәрхетдинова**



Булат Җиһаншин



Салават Миннеханов



Равил Галиев



- ***Халкым минем буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәтләр, бәйрәмнәрне саклап яши. Шулардан: Сабантуй, Сөмбелә, Нәүрүз бәйрәмнәре… Каз өмәсе, карга боткасы, сөрән сугу кебек йолаларны да онытмыйлар безнең якларда. Халкыбызның милли бәйрәмнәре шәһәр һәм районыбыздагы барлык милләтләрнең дуслык бәйрәменә әверелде.***


Я
ИЗНЬ!


АЗНАКАЙ
AZNAKAY
АЗНАКАЕВО

**Кешелекнең үзе шикелле үк,**
**Борынгыдан килә бәйрәмнәр.**
**Шатлыкларын бәйрәм итә кеше,**
**Бәйрәмнәрдә олы ямьнәр бар**









**“Чатыр тауда җыен” фольклор фестивале**

# Минем укучыларым


РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ДИПЛОМ

ПРИЗЕРА РЕСПУБЛИКАНСКОЙ ОЛИМПИАДЫ ШКОЛЬНИКОВ

по татарской литературе

НАГРАЖДАЕТСЯ

Гарипова Лейсан Ришатовна,

обучающий(ая)ся 11 класса

МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №2 г. Азнакаево» Азнакаевского муниципального района Республики Татарстан

Председатель оргкомитета А. И. Поминов

М. П. Регистрационный № 576

16 февраля 2017 года





РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ДИПЛОМ

ПРИЗЕРА РЕСПУБЛИКАНСКОЙ ОЛИМПИАДЫ ШКОЛЬНИКОВ

по татарской литературе

НАГРАЖДАЕТСЯ

ГАРИПОВА ЛЕЙСАН РИШАТОВНА,

обучающаяся 9 класса

МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №2» Азнакаевского муниципального района

Председатель оргкомитета А. И. Поминов

М. П. Регистрационный № 119

15 февраля 2015 года

**Бәйгеләрдә, олимпиадаларда бик теләп катнашам. Берничә ел рәттән татар әдәбиятыннан район, республика олимпиадаларында җиңүче булдым!**

# “Татарстан – Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе
# “Тамчы - шоу” интеллектуаль күңел ачу тапшыруы










*Татар кызы, татар уллары без,*
*Саклыйк, яклыйк туган илебезне.*
*Без көч биреп яшәтергә тиеш*
*Җандай газиз туган телебезне*





***Безнең Азнакай ягына рәхим итегез!***
***Яратып каршы алырбыз,***
***хөрмәтләп кунак итәрбез!***



**Игътибарыгыз өчен рәхмәт!**